Казан шәһәре Совет районы “181 нче күп профильле мәктәп”
№7 март, 2023 ел

# «Күкнең җиденче катында»




***Кадерле укытучылар, укучы кызларыбыз!***
***Зур бәхетләр юлдаш булсын сезгә***
***Көнегезне шатлык бизәсен.***
***Җир йөзенең бөтен матурлыгын***
***Килә сезгә бүләк итәсе.***
***Теләкләрнең кайсын теләсәк тә,***
***Аз булыр күк сезнең хөрмәткә,***
***Аллаһ сезгә озын гомер бирсен***
***Без калабыз шушы теләктә!***

# Мәктәбебез тормышы “кайнап” тора...

## Волейбол ярышлары

27 нче март көнне Казан шәһәре укучылары арасында волейбол буенча ачык шәхси һәм команда беренчелегенә ярышлар уздырылды.
Ярыш Татарстан Республикасының волейбол федерациясе тарафыннан расланган кагыйдәләр буенча үткәрелде.
Шәхси беренчелектә егетләр һәм кызлар арасында 3 урын билгеле булды.
Призлы урыннарны алган уенчылар грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

## “Строй һәм җыр” ярышы

28 нче февраль көнне мәктәбебезнең гары сыйныф укучылары 161 нче мәктәптә Ватанга мәхәббәт тәрбияләү максатыннан Ватанны саклаучылар көненә багышланган “Строй һәм җыр” ярышында катнаштылар.
Конкурс укучыларга танып-белү, сәнгать-эстетик, физик үсеш һәм патриотик тәрбия бирү өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән.
Һәр команда конкурска җаваплылык белән әзерләнгән. Жюри укучыларның смотрга әзерлеге югары дәрәҗәдә булуын билгеләп үтте.
Барлык отрядларның командирлары үзләрен бик яхшы яктан күрсәттеләр, ә бит аларга бик авыр туры килде: алар үзләре өчен дә, бөтен команда өчен дә җавап бирделәр. Җаваплылык йөген һәр командир тойса да, үз командасын беркем дә сынатмады.
Җиңүчеләрне билгеләү җиңел булмады. Судьялар бик озак киңәшләштеләр. Аз гына аермалыклар белән җиңүчеләр билгеләнде. Безнең мәктәбебез 5 нче урынны яулады. Киләчәктә аларның беренче өчлеккә керүләрен теләп калабыз.

## “Җаннарда искиткеч омтылышлар” исемендәге Бөтен Рәсәй бәйгесе

Мәктәбебездә икенче ел “Җаннарда искиткеч омтылышлар” исемендәге Бөтен Рәсәй бәйгесе уздырыла. Быел да бу бәйге безнең мәктәбебездә узды. Бәйгедә Рәсәйнең төрле регионнарыннан килгән укучылар катнашты. Нәфис сүз осталары шигырь сөйләү осталыкларын күрсәттеләр.
Эзләнү эшләре дә югары дәрәҗәдә язылган иде.
Театр сәнгате, вокал да югары дәрәҗәдә узды. Барлык катнашучыларыбызны котлыйбыз!

## Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев исемендәге республика фәнни-гамәли конференциясе

27 нче март көнне мәктәбебездә **Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев исемендәге республика фәнни-гамәли конференциясе** булып узды. 32 шәһәрдән 360 проект эше кабул ителде. 312 эш икенче этапка үтте. Мәктәбебездә 9 секция эшләде, 42 педагог хезмәте тикшерелде. Конференция ачылышы, секция эше бик югары дәрәҗәдә алып барылды.
Оештыручыларга, экспертларга, килгән кунакларга рәхмәтебезне белдерәбез!

## “Йолдызлар атылуы”

Мәктәбебез укытучылары дәрес укытулары белән генә чикләнмичә, төрле бәйгеләрдә дә катнашырга өлгерә. Әйтик, **“Йолдызлар атылуы”** бәйгесе.
Җыр-бию, мода һ.б. алар үзләренең талантларын күрсәттеләр. Зәвыклы киемнәр, матур биюләре белән тамашачыларны “таң калдырды” лар.
Район фестивалендә Гран-при яуладылар. Афәрин!



## 9 нчы сыйныф укучысы Киләчәк укытучысын ничек күрә? Сезгә әлеге сорауга инша тәкъдим итәбез.

**Киләчәк укытучысын мин ничек күрәм.**

Хәзерге заманда бик актуаль киләчәк йортлар,киләчәк машиналар турында күзаллау,сөйләшү. Машиналар һавада очып йөрер дип көтелә,йортлар күз алдына да китерә алмаслык биеклектә,төрле геометрик формаларда килеп баса.

Ә кичләчәк кешесе нинди булыр соң?

Киләчәк укытучысы нинди булыр? Бер караганда, цифрлы технологияләр бик алга киткән заманда, мәктәпләрдә робот-укытучылар килер дип көтелә. Ә андый робот укытучы белән кешене чагыштырып буламы соң? Юк, шул.Чөнки роботлар җансыз.Ә укытучы балалар белән эш итүче, аларның эчке күңелләрен аңлаучы,тоючы.Минем уйлавымча, балалар белән эш итүче һөнәр ияләренә җанлы кешеләр кирәк.

Киләчәк укытучыларын яңа буын балаларын аңлап,алар белән эш иткәндә аларның теләкләрен ишетеп , һәр кылган яхшы эшләрен кабул итеп ,акыл белән балаларга дөрес юл күрсәтүче итеп күрәм.

Дәресләр парта артында утырып,балаларны ялыктырып түгел,ә яңа укыту ысуллары,формалары белән укытылачык итеп күзаллыйм .Дәресләр кызык, җанлы, истә калырлык итеп оештырылган булырга тиеш дип уйлыйм.

Киләчәк укытучысы-үз эшенең остасы,күп белүче,күп укучы.Ул һәрвакыт ярдәмгә килүче,күз карашыннан балаларны аңлаучы.

Укытучы -ул үз эченә күп һөнәр иясен туплаган,ә киләчәк укытучысы - очкын,ялкын булырлык кеше!

Асланова Нәргиз

**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
**Тираж** – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.
**Редколлегия әгъзалары:** Соколова София, Сафина Камилла, Овезова Ләйлә, Ибраһимова Сабина